КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 31 июль г.Казань № 912

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 21 ноябрь, 890 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 12 октябрь, 905 нче; 2020 ел, 30 май, 441 нче, 2023 ел, 16 май, 597 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктта:

8.1 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Системада урнаштырылган барлык мәгълүматның резерв күчермәсен тәэмин итүне, саклауны һәм зарарланган яисә җимерелгән очракта резерв күчермәләрен торгызуны тәэмин итәргә;

аңа карата санкциясез керү нәтиҗәсендә модификацияләнгән яисә юкка чыгарылган мәгълүматны кичекмәстән торгызу чараларын гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;»;

8.2 пунктчада:

икенче абзацта «дөреслек һәм актуальлек» сүзләрен «дөреслекне һәм актуальлекне оештыруны» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «актуальлек» сүзен «актуальлекне оештыру» сүзләренә алмаштырырга;

8.3 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«әлеге Нигезләмәнең 11 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат системаларына Системадан тапшырыла торган белешмәләрнең актуальлеген тәэмин итәргә, ә белешмәләрнең дөрес булмавы ачыкланган очракта - аларны үзгәртүне тәэмин итәргә;»;

9 пунктның 9.3 пунктчасындагы бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Системада эшкәртелә торган шәхси мәгълүматны таратмау;»;

11 пунктның дүртенче һәм бишенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» - Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәр эшли торган муниципаль берәмлекнең дәүләт органы, җирле үзидарә органы исеме турында мәгълүмат бирү өлешендә;

«Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм алар буйсынуындагы учреждениеләрнең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплары» дәүләт мәгълүмат системасы - Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын һәм Татарстан Республикасында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр турында мәгълүмат аралашуның аерым регламенты кысаларында белешмәләр тапшыру өлешендә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 5 июнь, б-1186 нчы боерыгына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 22 октябрь, б-2698 нче боерыгы белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге күрсәтмә белән расланган «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында кулланучылар эше регламентында:

2.1 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктта:

унынчы абзацта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

унсигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү күрсәткечләре («Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте

турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә билгеләнгән вазыйфаи окладлар, классны чин өчен оклад, өстәмә түләүләр күләмнәре);»;

4.2 пунктта «ике көн» сүзләрен «ике эш көне» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 4.2$^1$ пункт өстәргә:

«4.2$^1$. Системадан файдаланучы кадрлар документларын «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» һәм «Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм алар буйсынуындагы учреждениеләрнең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплары» дәүләт мәгълүмат системаларының функциональ кулланучылары арасында мәгълүмати хезмәттәшлек регламенты кысаларында билгеләнгән исемлек буенча «Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм алар буйсынуындагы учреждениеләрнең бухгалтерлык исәбе һәм хисаплары» дәүләт мәгълүмат системасына үзгәрешләр барлыкка килгән көннән соң ике эш көне дәвамында җибәрүне тәэмин итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин